СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2016 с. Сарманово № 51

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен һәм арендага бирү тәртибен бирү өчен өченче затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында**

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда шартларында муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы, нигезендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1нче кушымта нигезендә озак сроклы нигездә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына файдалануга бирү өчен өченче затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген расларга.
2. 2 нче кушымта нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен Сарман муниципаль районы (җир кишәрлекләреннән тыш) муниципаль мөлкәте исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) арендага бирү тәртибен расларга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районыСовет рәисе Ф. М. Хөснуллин